**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 март № 167

г. Казань

Хосусыйлаштыру процессында төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрдәге Татарстан Республикасы милкендә булган өлешләр белән идарә итү тәртибен раслау турында

Хосусыйлаштыру процессында төзелгән, өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре белән нәтиҗәле идарә итү максатларында, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 ел, 21 декабрь, ФЗ-178 нче Федераль законның 39 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 ел, 26 июль, ТРЗ-43 нче Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Хосусыйлаштыру процессында төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрдәге Татарстан Республикасы милкендә булган өлешләр белән идарә итү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\167.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 24 март, 167 нче карары белән расланды

Хосусыйлаштыру процессында төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрдәге Татарстан Республикасы милкендә булган өлешләр белән идарә итү тәртибе

1. Устав капиталындагы өлеше Татарстан Республикасы милкендә булган җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьтә катнашучының (алга таба тиешенчә – җәмгыять, катнашучы) хокукларын Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) гамәлгә ашыра.

2. Вәкаләтле орган әлеге Тәртип нигезендә катнашучыларның гомуми җыелышының (алга таба – гомуми җыелыш) көн тәртибенә мәсьәләләр кертүне, җәмгыятьнең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы буларак билгеләү өчен кандидатларны тәкъдим итүне, чираттан тыш гомуми җыелыш үткәрү турында таләпләр белдерүне, чираттан тыш гомуми җыелыш чакыруны һәм гомуми җыелышта тавыш бирү өчен вәкилне билгеләүне (таныклык тапшыру) гамәлгә ашыра.

Гомуми җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча катнашучы – Татарстан Республикасы позициясе вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы вәкиленә гомуми җыелышта тавыш бирү өчен язма рәвештә бирелгән директивларда чагыла. Әлеге вәкил директивлар һәм вәкаләтле органның ышанычнамәсе нигезендә эш итә.

3. Катнашучы – Татарстан Республикасы хокуклары җәмгыятьнең эшчәнлек өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының (алга таба – тармак органы) тәкъдимнәре нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Катнашучы – Татарстан Республикасы позициясен әзерләү максатларында, вәкаләтле орган җәмгыятьтән алынган гомуми җыелыш үткәрү турындагы мәгълүматны (көн тәртибен һәм башка материалларны теркәп), гомуми җыелышны үткәрү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча, тармак органына җибәрә.

5. Чираттан тыш гомуми җыелыш үткәрү турындагы таләпләр беледерүгә бәйле булган, чираттан тыш җыелышның көн тәртибенә кертелергә тиешле мәсьәләләр һәм тиешле карарлар тәгъбирләрен үз эченә алган тәкъдимнәр гомуми җыелышны үткәрү турында мәгълүмат алган көннән биш көн эчендә тармак органы тарафыннан вәкаләтле органга җибәрелә.

Күрсәтелгән тәкъдимнәр, чираттан тыш җыелышның көн тәртибенә тәкъдим ителә торган мәсьәләне кертүне язмача нигезләп, шулай ук карар кабул итү өчен кирәкле материалларны теркәп кертелә.

Көн тәртибенә җәмгыятьнең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органын билгеләү турындагы мәсьәлә кертелгәндә, шулай ук кандидатлар хакында

мәгълүмат, шул исәптән тиешле кандидатлар турында эш урыныннан кадрлар хезмәтләре белешмәләре тапшырыла.

6. Тәкъдим ителә торган мәсьәләләр буенча тавыш бирүгә кагылышлы позицияне һәм тиешле карараларлар тәгъбирләрен үз эченә алган, еллык гомуми җыелышның көн тәртибенә мәсьәләләрне кертү һәм җәмгыятьнең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органын билгеләү өчен кандидатларны тәкъдим итү буенча тәкъдимнәр тармак органы тарафыннан вәкаләтле органга еллык гомуми җыелышны үткәрә торган елның 10 гыйнварына кадәр җибәрелә.

Алда әйтелгән тәкъдимнәр, аңлатма язуын һәм кирәкле материалларны, шулай ук (кирәк булган очракта) җәмгыятьнең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органын билгеләү өчен кандидатлар хакында мәгълүмат, шул исәптән тиешле кандидатлар турында эш урыныннан кадрлар хезмәтләре белешмәләре теркәп кертелә.

7. Гомуми җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирүгә кагылышлы тәкъдимнәр тармак органы тарафыннан вәкаләтле органга гомуми җыелышны үткәрү көненә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Әлеге тәкъдимнәр тәкъдим ителә торган карарларның язмача нигезләмәсен, шулай ук кирәкле материалларны теркәп җибәрелә.

8. Татарстан Республикасы вәкилләренә гомуми җыелышларда тавыш бирү өчен директивлар вәкаләтле орган тарафыннан рәсмиләштерелә.

9. Вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары), тармак органы һәм вәкаләтле орган арасында түбәндәгеләргә мөнәсәбәтле фикер каршылыклары булган очракта, килештерү киңәшмәсен үткәрүне тәэмин итә:

чираттан тыш гомуми җыелыш үткәрү турында таләп белдерүгә мөнәсәбәтле – вәкаләтле орган тармак органы позициясен алган көннән соң 15 көннән дә соңга калмыйча;

еллык гомуми җыелышның көн тәртибенә җәмгыятьнең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органын билгеләү өчен кандидатлар тәкъдим итү турында тәкъдимнәр кертү һәм башка мәсьәләләргә мөнәсәбәтле – еллык гомуми җыелыш үткәрә торган елның 15 гыйнварына кадәр;

гомуми җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тавыш бирүгә мөнәсәбәтле – аны үткәрү көненә кадәр 15 көннән дә соңга калмыйча.

Килештерү киңәшмәсендә килешенгән позиция булдырылмаган очракта, вәкаләтле орган җитәкчесе, күрсәтелгән киңәшмәне үткәргән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, кирәкле материалларны, шул исәптән якларның позицияләре нигезләнгән фикер каршылыклары исемлеген һәм тармак органы тәкъдимнәрен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

Бу очракта катнашучы – Татарстан Республикасы позициясе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан формалаштырыла.

___